# *Иж-Бубый авыл тарихы музее сайтыннан*

9 июнь - Иж-Бубый авыл тарихы музее өчен бик якын булган Альта Хаҗи кызы Мәхмүтованың туган көне, һәм үзебезнең язмабызны бүген аңа багышлыйбыз.
Казан Федераль университеты доценты, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты, Иж-Буби мәдрәсәсе тарихы, бертуган Нигъмәтуллин-Бубилар эшчәнлеге, Габдулла Бубиның кулъязмалары турында иң күп фәнни хезмәтләр авторы Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова Әгерҗе районы белән чиктәш Менделеевск районы Бәзәкә авылында туып үсә. Үзенең сөйләгәннәреннән белгәнебезчә, кечкенә чакта ук авылдашы, бик укымышлы кеше, мәгърифәтче Бубилардан гыйлем туплаган Таҗи-мулла абзый Шакировтан һәм әти-әнисе сөйләгәннәрдән ул данлыклы Иж-Буби мәдрәсәсе турында ишетә, һәм әлеге мәгълүмат аның күңеленә сеңеп кала.
Аның фәнни эшләрендә мәгърифәт, татарларда мәгариф, җәдитчелек хәрәкәте, патша хөкүмәтенең татарларга карата мөнәсәбәте һәрчак төп урынны алып торды. 1991 елда мәдрәсәнең 210 еллык юбилеена багышланган тәүге конференциядән башлап, ул - безнең даими кунагыбыз. Кунак кына түгел, әлеге зур җитди чараларда төп докладчыбыз, эшебездә киңәшчебез һәм остазыбыз.
2011 елда, нәкъ мәдрәсәнең 100 ел элек ябылган салкын январь аенда, Бертуган Бубилар исемендәге Иж-Бубый урта мәктәбе өстендә дә кара болытлар уйный башлаган иде. Бу турыда хәбәр Альта Хаҗиевнага кичтән барып ишетелә, ә икенче иртәдә инде ул Казаннан мәктәпне яклап авылга килгән делегациянең иң алдынгы сафларында иде. Шул ук иртәдә авылда үткәрелгән җыенда Альта ханым мәктәпне ябарга маташучыларга үзенең саллы сүзләрен җиткерде, аңлатты, дәлилләде. Һәм шуның нәтиҗәсе: Бертуган Бубилар исемендәге мәктәп районның база мәктәбе буларак эшчәнлеген дәвам иттерә.
Алты дистә елга якын Бубилар темасын өйрәнеп халыкка җиткерүче Альта Хаҗиевнаның фәнни монографияләре, газета-журналлардагы мәкаләләре, конференция-симпозиумнарда ясаган чыгышлары авыл тарихын өйрәнүчеләр, аның белән кызыксынучылар өчен төп кулланмаларның берсе булып тора.
Шушындый фидакарь, хәзер һәм алга таба да күп эшләр башкарырга яныпторучы Альта апабызны туган көне белән котлыйбыз, аңа зур рәхмәтләр әйтеп, ныклы сәламәтлек, хәерле озын гомер, иҗади уңышлар теләп калабыз.



Казан Федераль университеты доценты, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты; Иж-Буби мәдрәсәсе тарихы, бертуган Нигъмәтуллин-Бубилар эшчәнлеге, Габдулла Бубиның кулъязмалары турында иң күп фәнни хезмәтләр авторы Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова.



Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова (икенче рәттә уртада) Иж-Буби мәдрәсәсенең оешуына 210 ел тулу уңаеннан үткәрелгән халыкара фәнни конференциянең мәртәбәле кунаклары арасында.
1991 ел, Иж-Бубый.



Иж-Буби мәдрәсәсенең оешуына 220 ел тулу уңаеннан үткәрелгән халыкара фәнни конференциядән күренеш. Президиумда уңнан сулга беренче рәттә Мәктәп тарихы музее җитәкчесе Рәмзия Арслан кызы Хәлиуллина, Калифорния университеты профессоры Азадә-Гайшә Рорлих, тарихчы галимә Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова, Әгерҗе район башлыгы Рафис Фәрит улы Сәетов.
2001 ел, Иж-Бубый.




Иж-Буби мәдрәсәсенең оешуына 225 ел тулу уңаеннан үткәрелгән фәнни конференциядән күренеш.
Трибуна артында якташыбыз галим Раиф Фәтхелбаян улы Мәрданов.
Президиумда уңнан сулга беренче рәттә тарихчы галимә, язучы Ф.Ә.Бәйрәмова, тарихчы галимә А.Х.Мәхмүтова, РТ Мәгариф министрының беренче урынбасары Д.М.Мостафин, Әгерҗе район башлыгы Ф.Г.Габбасов, Әгерҗе мәгариф бүлеге җитәкчесе Р.Г.Гарифуллина. Икенче рәттә уңнан беренче Мәктәп тарихы музее җитәкчесе Р.А.Хәлиуллина.
2006 ел, Иж-Бубый.



Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова Иж-Буби мәдрәсәсенең оешуына 230, Гобәйдулла Бубиның туына 145, Габдулла Бубиның туына 140 ел тулу уңаеннан үткәрелгән тантанада Габдулла Бубиның "Хатыннар" китабын тәкъдир итә.
2011 ел, Иж-Бубый.



Иж-Бубый авылы тарихын торгызучылар һәм бер төркем тарихчы галимнәр Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Иж-Бубый» мәдрәсәсенең 230 еллыгына һәм Габдулла Бубыйның тууына 140 ел тулуга багышлап уздырылган «Иж-Буби мәдрәсәсе: мәгърифәт үзәге һәм аның татар халкы тарихын һәм мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше» фәнни конференциясендә.
2011 ел, Казан.




А.Х.Мәхмүтова - Мәктәп тарихы музеен оештыручы ветеран педагог Р.А.Хәлиуллинаны искә алу кичәсендә төп чыгыш ясаучы.
2013 ел, Иж-Бубый.




А.Х.Мәхмүтова Укучыларның Бертуган Бубилар исемендәге беренче төбәкара фәнни укуларында җиңүчеләр һәм чараның кунаклары арасында.
2014 ел, Иж-Бубый



Мәгърифәтче, педагог, дөньяда беренче хатын-кыз казыя Мөхлисә Бубиның тууына 150 ел тулу уңаеннан үткәрелгән төбәкара фәнни конференциядән күренеш.

ТР Мөселманнары мөфтиятенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин А.Х.Мәхмүтовага Камил хәзрәт Сәмигуллин имзалаган Рәхмәт хатын тапшыра.

Президиумда язучы, драматург, Мөхлисә Бубиның язмышына багышланган "Үлеп яратты" әсәренең авторы Ркаил Зәйдулла.

2019 ел, Иж-Бубый.



Альта Хаҗи кызы Мәхмүтова Иж-Бубый авыл тарихы музееен оештыручы Раиф Мөхәммәтҗан улы Гәрәев белән.
2019 ел, Иж-Бубый.